**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 ел, 15 ноябрь** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Чукмарлы торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, җирләү урыннарын төзекләндерү традицины (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Чукмарлы торак пунктында урамнарда яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);

3) Чукмарлы торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттә автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (ягулык-майлау материаллары алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар яныгылау Чукмарлы торак пунктында территорияне төзекләндерү (газ косилкасы өчен ягулык-майлау материаллары алу);

5) Чукмарлы торак пунктында янгын куркынычсызлыгы буенча чараларны тәэмин итү (2 дана янгын ранеецлар, мотопомпа өчен ГСМ) .

3. Җыен нэтиҗэлэрен Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин